РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.09.2021 1342-п

Саба муниципаль районы халкының тузган торагын сүтүдән төзелеш чүп-чарын чыгаруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан шәхси тузган торак йортларны ишүдән һәм сүтүдән төзелеш чүп-чарын чыгаруга бәйле чыгымнар өлешен (өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча) финанс белән тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы халкының тузган торагын сүтүдән төзелеш чүп-чарын чыгаруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районышың http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 30 сентябрендәге
1342-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

# Саба муниципаль районы халкының тузган торагын сүтүдән төзелеш чүп-чарын чыгаруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибе

## 1. Субсидия бирү турында гомуми нигезләмәләр

**1.1.** Әлеге Тәртип, Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан тузган торак йортларны ишүдән һәм сүтүдән төзелеш чүп-чарын чыгаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә (өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча), Саба муниципаль районы бюджетыннан шәхси эшкуарларга һәм юридик затларга субсидияләр бирү механизмын (алга таба - субсидияләр, субсидияләр алучылар) билгели.

**1.2.** Субсидия бирүнең максаты - Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан шәхси иске торак йортларны ишүдән һәм сүтүдән төзелеш чүп-чарын чыгаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен (өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча) финанс белән тәэмин итү.

**1.3.** Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җирле үзидарә органы булып тора, аңа, бюджет акчаларын алучы буларак, Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә, субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән (алга таба-баш күрсәтмә бирүче).

**1.4.** Субсидия бирү ,әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга, тиешле елга һәм план чорына, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты турында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

**1.5.** Субсидияләр алучыларны сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

– Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан иске торак йортларны ишүдән һәм сүтүдән төзелеш чүпләрен чыгару буенча физик затларга күрсәтелгән хезмәтләрнең бәясе 1 м3 өчен 87,50 сумнан артмый;

– субсидия алучы I-IV класслы куркыныч калдыкларны җыю, транспортлау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлекне тормышка ашыруга лицензиягә ия;

– субсидия алучы Саба муниципаль районы территориясендә теркәлгән;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә чүп-чар чыгару эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

**1.6.** Субсидия алучыга субсидия бирү турында килешү төзү датасына кадәр 15 эш көненнән дә артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килү шарты белән бирелә:

субсидия алучыларның Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булырга тиеш түгел;

Саба муниципаль районы бюджетына, шул исәптән башка хокукый актларга туры китереп бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурыч һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты алдында башка срогы чыккан бурыч булмау;

субсидия алучылар - юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучыларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә субсидия алучылар - шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеге шәхси эшкуар буларак туктатылган булырга тиеш түгел;

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимын тәкъдим итүче һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (оффшор зоналар) үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яисә территориядә теркәлгән, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашуы өлеше булган россия юридик заты яки чит ил юридик заты булып тормый, тулаем алганда, 50 проценттан артып китә;

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетыннан, әлеге Тәртипнец 1 пунктында күрсәтелгән максатларга, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алучы булып тормый.

**1.7.** Субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше - төзелеш чүпләрен чыгару буенча хезмәтләр күрсәтү.

## 2. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе.

**2.1.** Саба муниципаль районыныц Финанс-бюджет палатасы (алга таба - Палата) теркәлергә тиешле документлар белән бергә субсидия бирү турында гаризаны бирелгән көнендә номер, мөһер сугылган һәм тегеп ябыштырылган журналда кабул итә һәм терки.

**2.2.** Субсидияләр алу өчен, алучылар, Палатага түбәндәге документларны тапшыралар:

– үзенец түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2015 елныц 22 июлендәге 1001-п номерлы карары белән расланган форма буенча субсидия бирү турында гариза;

– субсидия алучының гамәлгә кую документларыныц, шулай ук аларга карата барлык үзгәрешләр турында документларның күчермәләрен;

– субсидия алучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы кул куйган, оешманың әлеге Тәртипнең 1.6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында белешмә;

– физик затларга күрсәтелгән хезмәтләр өчен шартнамәләрнең күчермәләрен;

– төзелеш чүп-чарын чыгаруны раслау максаты белән, шулай ук авыл (шәһәр) җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан имзаланган, физик затларга хезмәт күрсәтү актларының күчермәләрен;

– күрсәтелгән хезмәт өчен физик зат тарафыннан түләү фактын раслый торган түләү документларының күчермәләрен;

– 1 нче кушымта нигезендә тиешле субсидия турында белешмә-исәп;

– хезмәтләр күрсәтү адресы буенча тузган торак йорт булу турында җирле үзидарә органы белешмәсе.

**2.3.** Субсидия алучы үз инициативасы буенча түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

– салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмауны расслый торган документ

– юридик затны дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсен яки юридик затларның бердәм дәүләт реестрын теркәү кәгазе;

– салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

– Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Субсидия алучы әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Палата күрсәтелгән документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Тәкъдим ителгән документларның күчермәләре субсидияләр алучы тарафыннан таныклана.

**2.4.** Палата әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның дөреслеген тикшерә һәм ,субсидия бирү турындагы мәсьәләне карау өчен, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2018 елның 19 мартындагы 303-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр алу һәм җиңүчеләрне билгеләү өчен гаризаларны карау һәм бәяләү комиссиясенә юридик затларның гаризаларын кушымта итеп бирелә торган документлар белән тапшыра

**2.5.** Документлар һәм материаллар Палатадан алынганнан соң комиссия аларны карый һәм субсидия бирү мөмкинлеге турында карар чыгара, яки,сәбәпләрне күрсәтеп, субсидия бирүдән баш тарта.

**2.6.** Комиссиянең уңай карары булганда баш күрсәтмә бирүче 10 эш көне дәвамында субсидия бирү турында шартнамә төзи һәм үзенең Саба районы буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Территориаль бүлегендә ачылган шәхси счетыннан субсидия алучының хисап счетына субсидияне күчерүне гамәлгә ашыра.

Субсидия бирү турында шартнамә 1 елга гамәлдә булу срогы белән төзелә.

**2.7.** Кабул ителгән карарның нәтиҗәләре турында хәбәрнамә Палата тарафыннан субсидия алучыга язма рәвештә, тиешле карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә саналган өч көн эчендә җибәрелә.

**2.8.** Субсидия бирү турында хәбәр, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында, субсидия бирү турында гаризалар кабул итү тәмамланган датага кимендә унбиш көн кала урнаштырыла.

**2.9.** Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып була:

– субсидия алучының әлеге Тәртипнең 1.5 һәм 1.6 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килмәве;

– субсидия алучы тарафыннан таншырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

– субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы;

– бюджет йөкләмәләре лимиты булмау.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында хәбәрнамәдә баш тартуның нигезләре күрсәтелә.

Бюджет йөкләмәләре лимиты җитмәгән очракта, субсидия, субсидия бирү турында гариза бирү чираты тәртибендә бирелә.

**2.10.**Субсидия 1 м3 чыгарылган төзелеш чүп-чары өчен 137,5 сум исәбеннән бирелә, әмма 1 шәхси торак йортка чыгарылган төзелеш чүп-чары 80 м3 тән дә артмаска тиеш.

### 3. Хисап бирүгә таләпләр.

**3.1.**Күрсәткечләргә ирешү турында хисапка карата таләпләр, аерым алганда, субсидия алучы тарафыннан күрсәткечләргә ирешү турында хисап бирү тәртибен, срокларын һәм рәвешләрен билгеләү, билгеләнми.

### 4. Субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп тору һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны гамәлгә ашыру турындагы таләпләр.

**4.1.** Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны тикшереп торуны бюджет акчаларын алучы буларак Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Башкарма комитеты башкара.

**4.2.** Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы һәм Саба муниципаль районының Башкарма комитеты субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерәләр.

**4.3.** Субсидия алучы тарафыннан бюджет акчаларын алучы буларак баш күрсәтмә бирүче һәм муниципаль финанс тикшерүенең вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Контроль-хисап палатасы тарафыннан уздырылган тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган очракта, бирелгән субсидия субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш

**4.4.** Бирелгән субсидияләр субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактларын ачыклау буенча Башкарма комитетның тиешле таләпләрен алган көннән алып 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

**4.5.** Күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемenә ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

**4.6.** Бирелә торган документларның дөреслеге, бюджет акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалану, коррупциягә каршы законнарны үтәү өчен җаваплылык субсидия алучыларга йөкләнә. Хокук бозучыларга карата гамәлдәге законнарда каралган җаваплылык чаралары кулланыла.

Саба муниципаль районы халкының тузган торагын сүтүдән төзелеш чүп-чарын чыгаруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче номерлы кушымта

Раслыйм:
Учреждение Җитәкчесе

________________ Ф.И.АИ.

Мөһер урыны

**Саба муниципаль районы халкының тузган торагын сүтүдән төзелеш чүп-чарын чыгаруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетыннан бирелергә тиешле субсидия турында белешмә-хисап**

| Хезмәтнең исеме/ күрсәтелгән хезмәт урынының адресы | Чыгарылган төзелеш чүп-чары күләме, $м^3$ | 1 $м^3$ төзелеш чүп-чарын чыгару бәясе, сум. | Тиешле субсидияләр суммасы, мең сум (гр.2*гр.3) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |

Баш хисапчы ________________ Ф.И.АИ.